| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2020 Казан шәһәре № 3-2/тп-2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен 2020 елга стандартлаштырылган тариф ставкалары, максималь егәрлек берәмлеге өчен ставкалар һәм түләү хисаплау буенча формулалар билгеләү турында» 2019 елның 18 декабрендәге 6-140/тп номерлы карары-ның 1 нче кушымтасындагы 1 нче табли-цасына үзгәреш кертү хакында

Техник хатаны юкка чыгару максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен 2020 елга стандартлаштырылган тариф ставкалары, максималь егәрлек берәмлеге өчен ставкалар һәм түләү хисаплау буенча формулалар билгеләү турында» 2019 елның 18 декабрендәге 6-140/тп номерлы карарының 1 нче кушымтасындагы 1 нче таблицасына, аны киләсе редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1 нче таблица

сум/ялгау (өстәлгән хакка салым бәясен исәпкә алмыйча)

| Аталышы | электр белән тәэмин итүнең даими схемасы буенча | электр белән тәэмин итүнең вакытлыча схемасы <2> буенча |
|---|---|---|
| $C_1$ – Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2017 елның 29 августындагы 1135/17 номерлы боерыгы белән расланган Методик күрсәтмәләрнең 16 пунктында («б» пунктчасыннан тыш) күрсәтелгән чаралар буенча кулланучыларның энергия кабул итү | 24 332 | 24 332 |

| | | |
|---|---|---|
| җайланмаларын технологик ялгау чыгымнарын каплауга стандартлаштырылган тариф ставкасы, шул исәптән түбәндәге чаралар буенча: | | |
| $C_{1.1}$– челтәр оешмасы тарафыннан техник шартлар әзерләү һәм бирү | 15 052 | 15 052 |
| $C_{1.2}$– мөрәҗәгать итүченең техник шартларны үтәвен челтәр оешмасы тарафыннан тикшерү | 9 280 | 9 280». |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев